ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ТУКАЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕ
«МУСАБАЙ-ЗАВОД АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ» СОВЕТЫ

# КАРАР

«05» июнь 2024 ел №13/3

Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Мусабай-Завод авыл җирлеге муниципаль берәмлегенең җирле әһәмияттәге аерым мәсьәләләрен хәл итү буенча вәкаләтләренең бер өлешен тапшыру турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 15 статьясы 4 өлеше, Мусабай-Завод авыл җирлеге уставы нигезендә Мусабай-Завод авыл җирлеге Советы

КАРАР БИРДЕ:

1. Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Советына җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү буенча Мусабай-Завод авыл җирлеге Башкарма комитетының түбәндәге вәкаләтләрен Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Башкарма комитетына тапшыру турында мәсьәләне карарга тәкъдим итәргә:

җирләү эше мәсьәләләре буенча махсуслаштырылган хезмәт булдыру һәм аның эшчәнлек тәртибен раслау;

җирләү буенча хезмәтләр күрсәтүнең гарантияләнгән исемлеге нигезендә күрсәтелә торган хезмәтләр бәясен билгеләү.

2. Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Советы әлеге карарның 1 пунктында күрсәтелгән тәкъдимне кабул иткән очракта, Мусабай-Завод авыл җирлеге Башкарма комитетына:

Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Башкарма комитеты белән әлеге карарның 1 пунктында күрсәтелгән вәкаләтләрне тапшыру турында килешү төзергә;

Әлеге карарны гамәлгә ашыруны тәэмин итү максатында, бюджет законнары нигезендә 2024 елга, 2025 һәм 2026 еллар планы чорына Мусабай-Завод авыл җирлеге бюджеты турында Мусабай-Завод авыл җирлеге Советы карарына үзгәрешләр кертү турында карары проектын эшләргә һәм карауга тәкъдим итәргә.

3. Әлеге карарны «Татарстан Республикасы Тукай мунципаль районы Мусабай-Завод авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге уставы нигезендә махсус мәгълүмат стендларында һәм «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районының рәсми сайтында (tukay.tatarsatan.ru) рәсми рәвештә игълан итәргә.

4. Әлеге карар рәсми рәвештә игълан ителгән көннән үз көченә керә.

5. Әлеге карар үтәлешен контрольдә тотуны Мусабай-Завод авыл җирлеге Советының законлылык һәм хокук тәртибе буенча даими комиссиясенә йөкләргә.

Муниципаль берәмлек Башлыгы,
Совет Рәисе З.З. Хөсәинова